**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 12 маендагы 1415 номерлы карары**

## «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» 2025 халыкара икътисади форумын әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәрендә урам-юл челтәре участокларында юл хәрәкәтен оештыруны үзгәртү турында

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» 2025 халыкара икътисади форумын әзерләү һәм уздыру чорында иминлекне тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карарына таянып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. 2025 елның 12 маенда 19:00 сәгатьтән 2025 елның 18 маенда 07:00 сәгатькә кадәр түбәндәге участокларда, кирәк булганда, транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен чикләүне кертергә:

- А.Козин урамындагы 3 номерлы йорт каршында, Нигъмәтуллин урамы ягыннан Ф.Әмирхан урамы юнәлешендә;
- Декабристлар урамындагы 85Б номерлы йорт каршында, Горсоветская урамыннан М.Вахитов урамы юнәлешендә;
- Чистай урамындагы 47А номерлы йорт каршында, Ф.Әмирхан урамы ягыннан А.Бичурин урамы юнәлешендә;
- Карл Маркс урамы буенча, 6 номерлы йорт янында, Батурин урамы ягыннан уң як полоса буенча Миславский урамы юнәлешендә;

- Чернышевский урамы буенча, 39 номерлы йорт янында, Г.Исхакый урамыннан Мәскәү урамы юнәлешендә (уң як полоса);

- Островский урамы буенча, 35 номерлы йорт янында, Университет урамыннан Астрономия урамы юнәлешендә;

- Островский урамы буенча, 61 номерлы йорт янында, А.Айдинов урамыннан Пушкин урамы юнәлешендә (уң як полоса);

- Университет урамы буенча, 16 номерлы йорт янында, Профсоюз урамыннан Кремль урамы юнәлешендә;

- Большая Красная урамы буенча, 50 номерлы йорт янында, Гоголь урамыннан Жуковский урамы юнәлешендә (сул як полоса);

- Р.Зорге урамы буенча, 66Б номерлы йорт янында, Җиңү проспектыннан Ю.Фучик урамы юнәлешендә;

- Уң як Болак урамы буенча, 43 номерлы йорт янында («Азимут» кунакханәсе каршындагы муниципаль парковка);

- Сәетгалиев урамы буенча, Р.Яхин урамыннан Ташаяк урамы юнәлешендә;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген

саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**